МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ **БОЕРЫК**

09.12.2019 Казан ш. № 242-ОД

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының электр энергетикасы субъектларының инвестиция программаларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр керту хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына үзгәрешләр керту хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында» 2006 елның 16 июнендәге 310 номерлы карарын көчен югалткан дип тану турында» 2019 елның 16 сентябрендәге 834 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителүгә бәйле рәвештә б о е р ы к б и р ә м:

1. Электр энергетикасы субъектларының инвестиция программаларын раслау буенча Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.

2. Җыелма бүлеккә әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация системасында «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы Дәүләт мәгълүмат системасы составында Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Юридик бүлеккә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында законнарда билгеләнгән срокта дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Электр энергетикасы субъектларының инвестиция программаларын раслау буенча Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 30 апрелендәге 88-ОД номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары А.Ш.Хөсәеновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Министр А.Ә.Кәримов

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2019 елның 9 декабрендәге 242-ОД номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының электр энергетикасы субъектларының инвестиция программаларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент электр энергетикасы субъектларының инвестиция программаларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – дәүләт хезмәте).

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: «Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә электр энергетикасы өлкәсендә эшчәнлек башкара торган, шул исәптән электр, җылылык энергиясен һәм егәрлеген җитештерүне, электр энергиясен һәм егәрлеген сатып алуны һәм сатуны, кулланучыларны электр энергиясе белән тәэмин итүне, электр энергиясен тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтүне, электр энергетикасында оператив-диспетчерлык идарәсен, электр энергиясен (егәрлеген) сатуны, электр энергиясен һәм егәрлеген сату-алуны оештыруны гамәлгә ашыра торган юридик затлар (алга таба – электр энергетикасы субъектлары), шул исәптән электр энергетикасы субъектлары исәбенә кертелгән челтәр оешмалары (алга таба – челтәр оешмалары), аларның электр энергетикасы субъектларын инвестиция программалары (аларны финанслау чыганакларын билгеләүне дә кертеп) вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан яки вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе белән берлектә яки Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары тарафыннан раслана торган субъектлар исәбенә кертүнең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасы субъектларының инвестиция программаларын раслау турында» 2009 елның 1 декабрендәге 977 номерлы карары белән расланган Критерийларының 1, 1(1) пунктларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве шарты белән, һәм аларның түбәндәге критерийларның берәрсенә туры килүе шарты белән:

а) электр энергетикасы субъектының устав капиталында Татарстан Республикасының кимендә 50 процент өлеше булу, плюс бер тавыш бирү акциясе;

б) Электр энергетикасы субъекты инвестиция программасын финанслауны дәүләт тарафыннан җайга салынышы электр энергетикасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтенә карый торган электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләгәндә исәпкә алына торган инвестиция ресурсларыннан файдаланып финанслауны күздә тота;

в) Устав капиталында Татарстан Республикасы катнаша торган электр энергетикасы субъекты инвестиция программасында билгеләнгән егәрлеге 25 МВт һәм аннан югары булган генерацияләү объектын төзүне һәм (яки) билгеләнгән егәрлеген 25 МВт һәм аннан да югарыракка арттырып, генерацияләү объектын реконструкцияләүне (модернизацияләүне, техник яктан яңача коралландыруны) күздә тотучы электр энергетикасы субъекты;

г) Инвестиция программалары Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан расланган электр энергетикасы субъектлары, мондый инвестиция программаларына үзгәрешләр кертү зарурлыгы булганда.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәтен башкаручы – Министрлыкның энергияне саклау һәм энергия нәтиҗәлелеге бүлеге (алга таба – Бүлек).

1.3.1. Министрлык урнашкан урын: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Островский ур., 4 йорт, 8.

Бүлек урнашкан урын: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Островский ур., 8 йорт (каб. 204).

Министрлыкның эш графигы:

дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр

җомга: 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр.

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

тәнәфес: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: көн саен, эш көннәрендә, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

Керү шәхесне таныклый торган документ буенча.

Җәмәгать транспорты (6, 15, 17, 22, 28А, 29, 75, 89 номерлы автобуслар) белән «Педагогика университеты» тукталышына кадәр килергә кирәк.

1.3.2. Бүлекнең белешмә телефоннары: (843) 210-05-27, (843) 210-05-33.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://mpt.tatarstan.ru/. Министрлыкның электрон почта адресы: mpt@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Бүлек урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алучы, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү урыннарында урнашкан дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://mpt.tatarstan.ru/);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Министрлык урнашкан урын, аның белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайтының адресы, шулай ук электрон почтасы турында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк урнашкан урын һәм аның эш графигы турындагы мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.2, 1.3.1, 1.3.2, 1.3.3, 1.4, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, № 13, 1177 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергиясен күпләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларын раслау турында» 2004 елның 21 гыйнварындагы 24 номерлы карары белән расланган Электр энергиясен күпләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартлары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2004, № 4, 282 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып, алга таба – Стандартлар);

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү турында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, № 7, 776 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Энергия саклау турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр керту турында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, № 48, 5711 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасы субъектларының инвестиция программалары турында» 2009 елның 1 декабрендәге 977 номерлы карары белән расланган Электр энергетикасы субъектларының инвестиция программаларын раслау кагыйдәләре (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, № 49, 5978 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт функцияләрен үтәүнең административ регламентларын һәм дәүләт хезмәтләр күрсәтүнең административ

регламентларын эшләү һәм раслау турында» 2011 елның 16 маендагы 373 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 22, 3169 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасы субъектларының инвестиция программаларын раслау һәм аларны тормышка ашыруны тикшереп тору мәсьәләләре буенча РФ Хөкүмәтенең аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 16 февралендәге 132 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 23.02.2015, № 8, 1175 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып; алга таба – РФ Хөкүмәтенең 132 номерлы карары);

Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Челтәр оешмасы тарафыннан инвестиция программасы турында (инвестиция программасы һәм (яки) инвестиция программасына кертелә торган үзгәрешләр проекты турында) һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 21 гыйнварындагы 24 номерлы карарында расланган электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының 11 пунктындагы «ж» пунктчасының икенче - дүртенче, алтынчы, сигезенче һәм унынчы абзацларында күрсәтелгән, аны нигезли торган материалларны, күрсәтелгән формаларны тутыру кагыйдәләрен һәм челтәр оешмасы тарафыннан инвестиция программасы турында (инвестиция программасы һәм (яки) инвестиция программасына кертелә торган үзгәрешләр проекты турында) мәгълүматны һәм аны нигезләүче материалларны үз эченә алган электрон документларны ачу форматларына карата таләпләр раслау турында» 2016 елның 5 маендагы 380 номерлы боерыгы (Россия Юстиция министрлыгында 2016 елның 9 июнендә теркәлгән, теркәлү номеры – 42482, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Электр энергетикасы субъектының инвестиция программасын раслау турында карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштыру формасын раслау хакында» 2016 елның 20 декабрендәге 1357 номерлы боерыгы (Россия Юстиция министрлыгында 2017 елның 17 гыйнварында теркәлгән, теркәлү номеры – 45259, үзгәрешләрен исәпкә алып; алга таба – Россия Энергетика министрлыгының 1357 номерлы боерыгы);

Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Электр энергетикасы субъектының финанс планы формасын, әлеге форманы һәм электр энергетикасы субъектының финанс планы турында мәгълүматны үз эченә алган электрон документлар форматларына карата таләпләр раслау турында» 2017 елның 13 апрелендәге 310 номерлы боерыгы (Россия Юстиция министрлыгында 2017 елның 10 маенда теркәлгән, теркәү номеры – 46657);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 23 июлендәге 324 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә), (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 08.08.2007, № 30, 1056 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып; алга таба – Министрлык турында нигезләмә);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр керту хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы», 08.12.2010, №46, 2144 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.5. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр шуларга нигезләнеп кертелүче документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль районы (шәһәр округы) авыл җирлегендә оештырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Бу Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 1 п.).

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

Стандарт таләпләренең атамасы	Стандартка карата таләпләр эчтәлеге	Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт
2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы	Электр энергетикасы субъектларының инвестиция программаларын раслау	Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 1 декабрендәге 977 номерлы карары
2.2. Хезмәтне турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы	Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.	Министрлык турында нигезләмәнең 4.1.108 п. Кагыйдәләрнең 46 п.
2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама	Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: Россия Энергетика министрлыгының 1357 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча инвестиция программасын раслау турында Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталының электр энергетикасы субъектларының инвестиция программалары (инвестиция программалары проектлары) турында мәгълүмат, аларны гамәлгә ашыру, электр энергетикасы субъектларының инвестиция программаларын (инвестиция программалары проектларын) карап тикшерү һәм иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре турында хисаплар урнаштырыла торган	Кагыйдәләрнең 64-66 пп.

	бүлегендә (алга таба – системаның рәсми сайты) урнаштырылган карар һәм мөрәҗәгать итүчегә тиешле хәбәр җибәрү; инвестиция программасын раслаудан дәлилле баш тарту. Техник мөмкинлек тәэмин ителгәнчегә кадәр: инвестиция программасын раслау турында карарны системаның рәсми сайтына урнаштырганчы яисә Кагыйдәләрнең 9 пунктының бишенче абзацында күрсәтелгән очракларда инвестиция программасын раслау турында карарны рәсми сайт бүлегендә урнаштыруның техник мөмкинлеге вакытлыча булмаганда, инвестиция программасын раслау турында карар Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла; системаның рәсми сайтыннан файдаланып, мөрәҗәгать итүчегә инвестиция программасын раслау, инвестиция программасын раслаудан дәлилле баш тарту турында хәбәр җибәрелгәнчегә кадәр яки Кагыйдәләрнең 9 пунктындагы бишенче абзацында күрсәтелгән очракларда күрсәтелгән хәбәрне һәм (яки) дәлилле баш тарту турында хәбәрне системаның рәсми сайтыннан файдаланып җибәрүнең вакытлыча техник мөмкинлеге булмаганда, күрсәтелгән хәбәр һәм дәлилле баш тарту турында хат мөрәҗәгать итүчегә электрон элемтә чараларын кулланып, мөрәҗәгать итүченең инвестиция программасын раслау мәсьәләсе буенча Министрлык белән үзара хезмәттәшлек итү өчен җаваплы хезмәткәренең Министрлыкка җибәрелгән гаризада күрсәтелгән адресына җибәрелә	Кагыйдәләрне 8, 16, 63 пп. Кагыйдәләрнең 9 п. РФ Хөкүмәтенең 132 номерлы карарының 13 пункты
2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында	2.4.1. Министрлык, инвестиция программасы проектына карата Кагыйдәләрнең 49, 50 һәм 55 пунктларында каралган кисәтүләр һәм тәкъдимнәр булмаганда, тиешле гариза Министрлыкка җибәрелгән елның 1 ноябренә кадәр электр энергетикасы субъектының инвестиция программасын раслый, ә Кагыйдәләрнең 58-61 пунктларында каралган очракларда, – электр энергетикасы субъекты тарафыннан системаның рәсми	Кагыйдәләрнең 64 пункты

туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы	сайтында Кагыйдәләрнең 62 пункты нигезендә инвестиция программасының ахыргы проекты урнаштырылганнан соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы 165 календарь көне тәшкил итә. Әлеге срокка Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гамәлләр башкару вакыты керми. 2.4.2. Инвестиция программасын раслау Министрлык тарафыннан туктатыла: - әлеге Регламентның 2.9.1.1 пунктында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән көннән соңгы көннән башлап, әгәр мондый рәсми мөрәҗәгать электр энергетикасы субъекты тарафыннан җибәрелә торган гариза яки хәбәр Министрлыкка беренче мәртәбә җибәрелсә; - әлеге Регламентның 2.9.1.1 пунктында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне җибәргән һәм электр энергетикасы субъекты тарафыннан күрсәтелгән өстәмә материалларны тапшырмаган көннән башлап 7 календарь көне узгач, әгәр инвестиция программасын раслау Министрлык тарафыннан әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә тутатылмаган булса. Министрлык тарафыннан инвестиция программасын раслау эшен яңадан торгызу әлеге Регламентның 2.9.1.1 пунктында күрсәтелгән өстәмә материалларны алган көннән соң килүче көндә Министрлык тарафыннан инвестиция программасы проектын караунның билгеләнгән срокларын мондый инвестиция программасын раслауны туктатып тору срогының фактик озынлыгына озынайтып гамәлгә ашырыла. 2.4.3. Министрлык системаның рәсми сайтында инвестиция программасын раслау турында карарны Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы һәм Монополиягә каршы федераль хезмәт белән килештереп, Россия Энергетика	Кагыйдәләрнең 48 пункты

	министрлыгы раслаган форма буенча кабул иткән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштыра. Инвестиция программаны раслау турында карар системасының рәсми сайтында урнаштырылган көннән соңга калмыйча, Министрлык, системаның рәсми сайтыннан файдаланып, электр энергетикасы субъектына тиешле хәбәр җибәрә.	Кагыйдәләрнең 66 пункты
2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе	2.5.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра: 2.5.1.1. Гариза, анда түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш: а) электр энергетикасы субъекты турында (тулысынча аталышы, салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт теркәвенә алу номеры, электр энергетикасы субъектының гариза җибәрелә торган башкарма хакимият органы белән инвестиция программасын раслау мәсьәләсендә үзара хезмәттәшлек итүгә җаваплы хезмәткәре турында (исеме, фамилиясе, атасының исеме, вазыйфасы, телефон номеры, электрон почта адресы)), шулай ук электр энергетикасы субъектының әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән критерияләргә туры килүе турында белешмәләр; б) системаның рәсми сайтында инвестиция программасы проектын урнаштыру датасы һәм урыны (тулысынча электрон адрес); в) инвестиция программасы проектында Кагыйдәләрнең 19 пунктындагы «б», «в» һәм «г» пунктчаларында күрсәтелгән инвестиция проектлары булу; Продукциясенә (хезмәтләренә) бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салу озак сроклы җайга салу параметрлары нигезендә гамәлгә ашырыла торган электр энергетикасы субъекты тарафыннан җибәрелгән гаризада, әгәр үзенә карата гариза җибәрелә торган инвестиция программасына кертелүче	Кагыйдәләрнең 12 пункты

	үзгәрешләр проектында тиешле инвестиция программасын тормышка ашыру чорын озынайту күздә тотылса, түбәндәгеләр булырга тиеш: - электр энергетикасы субъекты аны озынайтырга планлаштыра торган озак сроклы җайга салу чорына озак сроклы җайга салу параметрларын билгеләү турында башкарма хакимият органы карарының реквизитлары (башкарма хакимият органының исеме, карарның датасы һәм номеры); - электр энергетикасы субъекты тарафыннан күрсәтелгән электр энергетикасы субъектына, аның аерымланган структур бүлекчәсенә яки ул үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган территориясенә карата билгеләнгән озак сроклы җайга салу чорын озынайтуның планлаштырыла торган озынлыгы турында мәгълүмат. 2.5.1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр – электр энергетикасы субъектлары, мөрәҗәгать итүчеләр - челтәр оешмаларыннан тыш, гариза белән бергә көчәйтелгән квалификацияле электрон имзадан файдаланып имзаланган электрон документлар формасында түбәндәге мәгълүматларны да җибәрә: а) электр энергетикасы субъектының инвестиция программасы проектын тормышка ашыру чорына эшчәнлек төрләре, шул исәптән дәүләт тарафыннан җайга салына торганнары, буенча бүленгән, инвестиция программасы проектын тормышка ашыруның 1 нче елыннан башлап, инвестиция программасы проектын финанслау чыганакларын һәм ысулларын һәм алдагы һәм агымдагы елларда электр энергетикасы субъектының финанс планын үтәү буенча хисап күрсәткечләрен күрсәтеп, финанс планы; б) инвестиция проектларының бәясен нигезләүче, инвестиция программасы проектында каралган, чыгымнар	Кагыйдәләрнең 13 пункты

	сводкасын, җыелма смета исәпләмәсен һәм шәһәр төзү эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә расланган инвестиция проекты буенча проект документациясе (алга таба – расланган проект документациясе) составында эшләнгән смета документациясенә аңлатма язуын үз эченә алган материаллар һәм мондый проект документациясен раслау турында карар күчермәсе, ә расланган проект документациясе булмаганда - мондый смета исәпләмәсен төзү вакытында барлыкка килгән бәяләрдә, шул исәптән эреләндерелгән смета нормативларыннан һәм башка төрле бәя мәгълүматларыннан (смета исәпләмәсендә файдаланылган документлар һәм бәя мәгълүматы чыганаклары күрсәтелә) файдаланып төзелгән инвестиция проектын тормышка ашыру бәясенең смета исәпләмәсе, смета исәпләмәсен әзерләү өчен бәя мәгълүматлары чыганаклары сыйфатында файдаланылган документларның күчермәләрен теркәп; в) инвестиция программасы проектын тормышка ашыру чорына фәнни-тикшеренү һәм (яки) сынау-конструкторлык эшләре буенча елларга бүленгән һәм эшләрнең эчтәлеген тасвирлаган программасы (булган очракта); г) инвестиция программасы проектында каралган инвестиция проектларының паспортлары. Инвестиция проекты паспорты дигәндә түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган документ аңлашыла: - электр энергиясенең күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары. шул исәптән табигый монополияләр субъектлары, билгеләмәсе буенча методик күрсәтмәләр нигезендә бер мәртәбә билгеләнә торган инвестиция проектының идентификаторы, электр энергиясен кулланучылардан, Россия Энергетика министрлыгы раслаган инвестиция проектлары идентификаторларыннан тыш. Инвестиция проектының идентификаторы инвестиция проектын тормышка ашырунның	

	барча срогында, шулай ук аны тормышка ашыруны төгәлләгәннән соң да үзгәрми; - инвестиция проектын тормышка ашыруның планлаштырылган максатлары, бурычлары, этаплары, сроклары һәм конкрет нәтиҗәләре; - инвестиция проектының күрсәткечләре, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре; - электр энергетикасы объектларын төзү (реконструкцияләү, модернизацияләү, техник яктан яңача коралландыру һәм (яки) демонтажлау) буенча инвестиция проектларын тормышка ашыру графиклары, аларның аталышларын, инвестиция проектларын тормышка ашыруның контроль этапларын башкаруның һәм капитал кертемнәрен, шул исәптән эшләрнең төп этапларына бүлеп, үзләштерүнең, шулай ук, алдагы һәм агымдагы елларда тормышка ашырыла торган инвестиция проектлары өчен хисап белешмәләрен күрсәтеп, кварталлар буенча төп чараларны кертүнең планлаштырылган срокларын һәм күләмнәрен дә кертеп; - инвестиция проектын тормышка ашыру барышы турында хисап мәгълүматы (тормышка ашырыла торган инвестиция проектларына карата), шул исәптән инвестиция проектын тормышка ашыру максатлары өчен башкарылган товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуларның нәтиҗәләре; - Россиянең Бердәм энергетика системасын яки технологик яктан изоляцияләнгән территориаль электр энергетикасы системаларын эшләтүнең технологик параметрларында чик дәрәҗәдә рөхсәт ителгән күрсәткечләрне (шул исәптән электр челтәренең көчәнеш дәрәҗәсен һәм үткәрү мөмкинлеген) электр энергетикасы объектларын төзү (реконструкцияләү, модернизацияләү, техник яктан яңача коралландыру һәм (яки) демонтажлау) буенча инвестиция проектында каралган	

	чараларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә электр энергетикасы объектларының эш параметрлары белән аңлатыла торган планлаштырылган рәвештә (максатчан) үзгәртү турында мәгълүмат; - төзелеше (реконструкциясе һәм (яки) демонтажлануы) инвестиция проектында күздә тотылган электр энергетикасы объектларын урнаштыру планлаштырылган урынны, шулай ук инвестиция программасы кысаларында булган һәм планлаштырылган чиктәш электр энергетикасы объектларын сурәтләгән карта-схемасы. Төзелеше (реконструкциясе һәм (яки) демонтажлануы) инвестиция проектында каралган федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны, җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру планлаштырылган урынны сурәтләгән карта-схема шәһәр төзелеше турында законнарда федераль әһәмияттәге, төбәк әһәмиятендәге, җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыруның планлаштырылган урыннары карталарына карата белдерелә торган территориаль планлаштыруның тиешле схемалары таләпләренә җавап бирергә тиеш. Карта-схеманы мәгълүмат белән тутыру картография материалларына карата белдерелә торган норматив документларның таләпләренә җавап бирергә тиеш. Карта-схема пространство белешмәләренең векторлы моделе формасында санлы картография нигезе катламнары базасында формалаштырыла. Электр энергетикасы субъектының финанс планы һәм инвестиция проектларының паспортлары Россия Энергетика министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы белән килешү буенча раслана торган формалар, күрсәтелгән формаларны тутыру кагыйдәләре һәм аларның форматларына карата таләпләр нигезендә электрон документлар формасында	

	җибәрелә. Әлеге пунктның өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән мәгълүмат форматларына карата Россия Энергетика министрлыгы раслый торган таләпләр нигезендә электрон документлар форматында җибәрелә. 2.5.1.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында мөрәҗәгать итүче Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра: а) эшләнеп беткән инвестиция программасы турында хәбәр һәм аңа теркәп бирелә торган материаллар; б) эшләнеп беткән ахыргы инвестиция программасы турында хәбәр һәм аңа теркәп бирелә торган материаллар; в) Министрлык тарафыннан соралган өстәмә материаллар; г) гаризаны кире алу (гамәлдән чыгару) турында таләп. 2.5.2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Регламентның 2.5.1.1-2.5.1.3 пунктларында күрсәтелгән документларны тапшыру һәм мондый документларны кабул итү системаның рәсми сайты бүлегендә гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүче системаның рәсми сайты аша әлеге Регламентның 2.5.1.1.1.1-2.5.1.3 пунктларында күрсәтелгән документларны тапшыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта, мондый документларны җибәрү көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгадан файдаланып, мәгълүматны электрон тапшыру чаралары яки электрон элемтә чаралары ярдәмендә электрон документлар рәвешендә гамәлгә ашырыла: Министрлыкның электрон почтасына: mpt@tatar.ru; Татарстан Республикасы Электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша.	Кагыйдәләрнең 48, 63 пунктлары Кагыйдәләрнең 9 пункты, РФ Хөкүмәтенең 132 номерлы карарының 13 пункты

	2.5.3. Эшләнеп беткән инвестиция программасы турында хәбәр, ахыргы инвестиция программасы турында хәбәр, шулай ук Министрлыкка электрон элемтә чараларын кулланып җибәрелә торган гаризаны кире алу (гамәлдән чыгару) турында таләп мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү турында белешмә мәгълүмат урнаштырылган бүлектә урнаштырылган тиешле документларның үрнәкләрен тутыру юлы белән, әлеге Регламентка 1-4 нче кушымталарга туры китерелгән формаларда әзерләнә.	
2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма	Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның ведомство буйсынуында торучы оешмалар карамагында булган документарны һәм мәгълүматларны тапшыру таләп ителми	
2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге	Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган	

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге	2.8.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен инвестиция программалары проектларын яисә гаризага һәм (яки) электр энергетикасы субъекты тарафыннан Министрлыкка җибәрелә торган хәбәрләргә теркәлә торган мәгълүматларны тәгаенләштерү зарурлыгы нигез булып тора. 2.8.1.1. Министрлык, әлеге Регламентның 2.8.1 пунктында күрсәтелгән нигез булган очракта, тапшыру формасын һәм аларга карата таләпләрне күрсәтеп, өстәмә материаллар сората, ә электр энергетикасы субъекты күрсәтелгән материалларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалап, рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән көннән башлап 7 календарь көне эчендә җибәрә. 2.8.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк.	Кагыйдәләрнең 48 пункты
2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре	Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә	
2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр	Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрне күрсәтү таләп ителми	
2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури	Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми	

булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп		
2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры	Дәүләт хезмәте күрсәтү турында таләп тапшыру һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алу чиратта көтүне күздә тотмый	
2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең рәсми мөрәҗәгатьнең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада	Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында, шул исәптән электрон рәвештәге, гаризасын теркәү гариза Министрлыкка килгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла	
2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның	Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла. Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук,	

исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр	хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла	
2.15. Дәүләт хезмәтенең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыт озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип),	Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: дәүләт хезмәте күрсәтелә торган Министрлык бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы; дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы; мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган вазыйфаи затларның кирәкле саны булуы; мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу; электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге; инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.	

дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтен һәм (яки) муниципаль хезмәтне алу турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гариза тапшыру (алга таба – комплекслы мөрәҗәгать) юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтен алу (шул исәптән тулы күләмдә) яки ала алмау мөмкинлеге	Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану; дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану; Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламентны бозган өчен прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы; мөрәҗәгать итүченең Министрлыктагы вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлек итү саны: дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча); Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Бүлек хезмәткәрләре белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү озынлыгы 15 минуттан артмый. Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гариза тапшыруны кертеп, дәүләт хезмәте дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша күрсәтелми. Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлык (http://mpt.tatarstan.ru/) сайтыннан, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://invest.gosuslugi.ru/) алынырга мөмкин. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.	
2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль	Дәүләт хезмәте системаның рәсми сайты аша күрсәтелә. Мөрәҗәгать итүче системаның рәсми сайты аша әлеге Регламентның 2.5.1.1.1.1-2.5.1.3 пунктларында күрсәтелгән документларны тапшыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта, мондый документларны җибәрү көчәйтелгән	Кагыйдәләрнең 9 пункты, РФ Хөкүмәтенең 132

принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр	квалификацияле электрон култамгадан файдаланып, мәгълүматны электрон тапшыру чаралары яки электрон элемтә чаралары ярдәмендә электрон документлар рәвешендә гамәлгә ашырыла: Министрлыкның электрон почтасына: mpt@tatar.ru; Татарстан Республикасы Электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша. Документларны электрон рәвештә тапшыруның мәҗбүри шарты булып аларның 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон рәвештә имзаланган булуы тора.	номерлы карарының 13 пункты

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге hәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүче консультацияләү;
2) гаризаны hәм аңа теркәлгән документларны кабул итә, терки hәм карый;
3) инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәрне үз эченә алган ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне формалаштыру hәм дәүләт органнарына hәм оешмаларга җибәрү;
4) инвестиция программасы проектын карау;
5) эшләнеп беткән инвестиция программасы проекты турында хәбәрне кабул итү, теркәү hәм карау;
6) эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәрне үз эченә алган ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне формалаштыру hәм дәүләт органнарына hәм оешмаларга җибәрү;
7) эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карау;
8) килештерү киңәшмәләрен үткәрү;
9) җайга салынмаган каршылыкларны карау;
10) ахыргы инвестиция программасы проекты турында хәбәрне кабул итү, теркәү hәм карау;
11) инвестиция программасын раслаудан дәлилле баш тартуны әзерләү;
12) инвестиция программасын раслау hәм мөрәҗәгать итүчегә тиешле карар җибәрү турында карар әзерләү;
13) расланган инвестиция программасына үзгәрешләр кертү.
14) техник хаталарны төзәтү;

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр күрсәтү.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен Бүлеккә шәхсән, телефон hәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча hәм дәүләт хезмәтен алу өчен башка мәсьәләләрдә, hәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы hәм дәүләт хезмәте алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итү, теркәү һәм карау.

3.3.1. Административ процедураны башлап җибәрү өчен әлеге Регламентның 2.5.1.1-2.5.1.3 пунктларында күрсәтелгән документлар белән мөрәҗәгать итүченең Министрлыкка мөрәҗәгать итүе нигез булып тора.

Гариза Министрлыкка җибәрелә:

а) Кагыйдәләрнең 11 пункты нигезендә:

челтәр оешмалары тарафыннан системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында Стандартларга туры китереп, иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча Министрлык тарафыннан расланачак эшләнеп беткән инвестиция программасы проекты турында мәгълүматны урнаштырган көннән, ләкин 5 апрельдән соңга калмыйча;

электр энергетикасы субъектлары тарафыннан, челтәр оешмаларыннан тыш, системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында Министрлык раслый торган инвестиция программасы проекты турында мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә мәгълүмат ачу көненнән соңга калмыйча;

б) Кагыйдәләрнең 69 пункты нигезендә территориаль планлаштыруның тиешле документын раслау турында вәкаләтле дәүләт хакимияте органы карары рәсми басылып чыккан көннән алып 15 календарь көне узганчы;

в) Кагыйдәләрнең 70 пункты нигезендә, системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында инвестиция программасына кертелә торган үзгәрешләр проектын урнаштыру көненнән соңга калмыйча.

Дәүләт хезмәте күрсәтү артыннан мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүче - электр энергетикасы субъекты әлеге Регламентның 2.5.1.1-2.5.1.2 пунктларында күрсәтелгән документларны тапшыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү артыннан мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүче - челтәр оешмасы әлеге Регламентның 2.5.1.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыра.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза Министрлыкка әлеге Регламентның 2.5.2 пункты нигезендә җибәрелә.

Бу вакытта дәүләт хезмәте күрсәтү артыннан мөрәҗәгать иткәнчегә кадәр мөрәҗәгать итүче - челтәр оешмасы, инвестиция программасы проекты хакында иҗтимагый фикер алышулар уздыру максатларында, системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында инвестиция программасы проектын урнаштыру турында, урнаштыру датасына һәм урынына (тулы электрон адресы) күрсәтелгән хәбәрне Тармакара кулланучылар советына җибәрә, шулай ук мондый хәбәрне «Интернет» челтәрендә үзенең рәсми сайтында да урнаштыра.

3.3.2. Министрлыкның эш башкару һәм контроль бүлеге белгече килгән гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны билгеләнгән тәртиптә теркәүне гамәлгә ашыра.

3.3.3. Гариза һәм аңа теркәп бирелгән документлар теркәлгәннән соң министр гаризаны карый, башкаручыларны билгели һәм министрның тикшерүдә тотучы урынбасары аша гаризаны Бүлеккә җибәрә.

3.3.4. Бүлекнең гаризаларны кабул итүче белгече түбәндәгеләрне тикшерүне гамәлгә ашыра:

а) «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясында күрсәтелгән шартлар үтәлешен тикшерүне күздә тотучы гаризаның электрон документы (электрон документлар пакеты) имзаланган көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынбарлыгын;

б) мөрәҗәгать итүчене әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр даирәсенә кертү максатларында гаризада һәм аңа теркәлә торган материалларда булган мәгълүматны;

в) гариза һәм аңа теркәп бирелә торган материалларның билгеләнгән таләпләргә һәм аларның электрон документларының форматларына (аерым алганда, Кагыйдәләрдә һәм әлеге Регламентта билгеләнгән таләпләргә) туры килү-килмәвен, шулай ук Кагыйдәләрдә һәм әлеге Регламентта билгеләнгән мәгълүмат составына туры килүен;

г) гаризада күрсәтелгән адрес буенча Интернет челтәрендә урнаштырылган инвестиция программасы проекты турында мәгълүматны, аны электрон рәвештә формасыеа һәм форматларына, шулай ук анда булган мәгълүматларның составына карата Стандартларда һәм Кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләргә җавап бирүен;

д) гаризада күрсәтелгән адрес буенча Интернет челтәрендә урнаштырылган инвестиция программасы проектын тормышка ашыру чорының ярашуын:

Кагыйдәләрнең 3 пунктында күрсәтелгән электр энергетикасы субъектының инвестиция программасын гамәлгә ашыру чорына карата таләпләргә;

мөрәҗәгать итүченең директорлар советының (күзәтчелек советының), ә директорлар советы (күзәтчелек советы) булмаганда – мөрәҗәгать итүче идарәсенең коллегиаль (бер кулдагы) башкарма органының яки вәкаләтле бүтән органының күчермәсе мөрәҗәгать итүче тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының 11 пунктындагы «ж» пунктчасының унөченче абзацы, 13 пунктының «д» пунктчасындагы алтынчы абзацы, 15.1 пунктының алтынчы абзацы яки 20.1 пунктының «д» пунктчасы нигезендә бастырып чыгарылган карары белән хупланган инвестиция программасы проектын тормышка ашыру чорына;

Кагыйдәләр нигезендә аның хакында иҗтимагый фикер алышулар уздырылган инвестиция программасы проектын тормышка ашыру чорына;

е) мөрәҗәгать итүченең Кагыйдәләрнең 8, 11 һәм 15 пунктларында билгеләнгән сроклары үтәвен:

иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын челтәр оешмасы тарафыннан Стандартларга туры китереп урнаштыруның;

иҗтимагый фикер алышу барышында кергән инвестиция программасы проектына тәкъдимнәр җыелмасын урнаштыруның;

Бүлеккә гариза җибәрүнең.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Бүлек белгече:

Регламентның әлеге пунктчасында «а», «в», «г», «д» пунктчаларында күрсәтелгән кисәтүләр булган очракта, тиешле кисәтүләрне һәм сәбәпләрне күрсәтеп, гаризаны караудан баш тарту турында дәлилле баш тарту әзерли һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрә;

Регламентның әлеге пунктчасында «б», «е» пунктчаларында күрсәтелгән кисәтүләр булган очракта, тиешле сәбәпләрне күрсәтеп, инвестиция программасын раслаудан баш тарту турында дәлилле баш тарту әзерли һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрә;

Регламентның әлеге пунктчасында күрсәтелгән кисәтүләр булмаган очракта, инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәр әзерли, ул мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә һәм системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында урнаштырыла.

3.3.5. Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны Министрлык кисәтүләрен бетергәннән соң, ләкин Министрлык тарафыннан кисәтүләр мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән көннән соң 10 календарь көне узганчы, инвестиция программасы проекты турында мәгълүмат ачылган көннән соңга калмыйча Министрлыкка җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

гаризаны теркәү – гариза Министрлыкка килгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

гаризаны карау һәм мөрәҗәгать итүчегә гаризаны караудан яисә инвестиция программасы проектын раслаудан баш тарту турында хат яисә инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәрне җибәрү – гариза теркәлгән көннән башлап 5 эш көне эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе булып түбәндәге гамәлләрнең берсе тора:

а) инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәрне системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында урнаштыру һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрү;

б) мөрәҗәгать итүчегә инвестиция программасын (инвестиция программасына кертелә торган үзгәрешләрне) раслаудан баш тарту турында нигезләнгән хат җибәрү;

в) мөрәҗәгать итүчегә гаризаны караудан баш тарту турында нигезләнгән хат җибәрү.

Әлеге административ процедура составына керүче административ гамәлләрне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып әлеге Регламентта әлеге мондый административ гамәлләрне башкаручы затлар буларак билгеләнгән вазыйфаи затлар тора.

3.4. Инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәрне үз эченә алган ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм дәүләт органнарына һәм оешмаларга җибәрү.

3.4.1. Административ процедураны башлау өчен инвестиция программасы проектын карауга алу турында хәбәрне системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында урнаштыру нигез булып тора.

3.4.2. Бүлек белгече системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында инвестиция программасы проектын карау өчен кабул итү турында хәбәр урнаштырылган көннән соңга калмыйча инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәрне, шулай ук гаризада булган белешмәләрне һәм гаризага теркәлә торган материалларны үз эченә алган рәсми мөрәҗәгатьләрне түбәндәге дәүләт органнарына һәм оешмаларына җибәрә (Кагыйдәләрнең 67 пунктындагы икенче абзацында һәм 69 пунктында каралган очраклардан тыш):

а) Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты;

б) «Бердәм энергетика системасының система операторы» АҖ филиалы «Урта Идел энергосистемасының берләштерелгән диспетчерлык берләшмәсе» (алга таба – Урта Идел БДБ), әгәр инвестиция программасы проектында түбәндәгеләр күздә тотылса:

проект буенча көчәнешенең номиналь классы 110 кВ һәм югары тәшкил итүче электр челтәрләре хуҗалыгы объектларын төзү (реконструкцияләү, модернизацияләү, техник яктан яңача коралландыру һәм (яки) демонтажлау);

билгеләнгән генерацияләү егәрлеге 5 МВт артып китә торган электр энергиясен җитештерү объектларын төзү һәм (яки) билгеләнгән генерацияләү егәрлеген 5 МВт һәм аннан югарыга арттырып, электр энергиясен җитештерү объектларын реконструкцияләү (модернизацияләү, техник яктан яңача коралландыру);

в) Россия Федерациясе Энергетика министрлыгы (алга таба – Россия Энергетика министрлыгы), әгәр инвестиция программасы проектында электр челтәрләре хуҗалыгы объектларын Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган бердәм илкүләм (гомумроссия)электр челтәренә кертү критерияләренә җавап бирә торган электр тапшыру линияләрен һәм (яки) трансформатор һәм башка төрле подстанцияләрне төзү һәм (яки) реконструкцияләү күздә тотылса.

3.4.3. Бүлек белгече, системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында челтәр оешмасының инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәр урнаштырылган көннән соңга калмыйча, мондый хәбәрне, шулай ук гаризада булган мәгълүматларны һәм гаризага теркәлә торган материалларны мәгълүматларны электрон тапшыру чараларыннан яки электрон элемтә чараларыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында Тармакара кулланучылар советына җибәрә (Кагыйдәләрнең 67 пунктының икенче абзацында һәм 69 пунктында каралган очракларда күрсәтелгән хәбәр җибәрелми).

3.4.4. Әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт органнары һәм оешмалар инвестиция программасы проектын Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә карый һәм Кагыйдәләрнең 46, 49, 50 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм срокларга туры китереп, инвестиция программасы проектын карау нәтиҗәләре буенча кисәтүләрне һәм (яисә) бәяләмәне Министрлыкка тапшыра.

Әлеге пунктчаларда билгеләнә торган процедуралар системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәр урнаштырылган көннән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт органнарына һәм оешмаларына җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

Әлеге административ процедура составына керүче административ гамәлләрне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып әлеге Регламентта әлеге мондый административ гамәлләрне башкаручы затлар буларак билгеләнгән вазыйфаи затлар тора.

3.5. Инвестиция программасы проектын карау.

3.5.1. Административ процедураны башлау өчен инвестиция программасы проектын карауга алу турында Министрлык карары нигез булып тора.

3.5.2. Бүлек белгече Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә инвестиция программасы проектын карауны гамәлгә ашыра.

Инвестиция программасы проектын карау барышында күрсәтелгән проектны яки гаризага теркәлә торган мәгълүматны тәгаенләштерү зарурлыгы барлыкка килгәндә, шул исәптән мөрәҗәгать итүче техник хаталары булган яки билгеләнгән таләпләргә туры килми торган итеп рәсмиләштерелгән документлар тапшырылганда, Бүлек белгече, тапшыру формасын һәм аларга карата таләпләрне күрсәтеп, өстәмә материаллар сората, ә электр энергетикасы субъекты күрсәтелгән материалларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалап, рәсми мөрәҗәгать килгән көннән башлап 7 календарь көне эчендә тапшыра.

Бүлек белгече тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән очракта, инвестиция программасын раслау әлеге Регламентның 2.8 пункты нигезендә туктатыла.

3.5.3. Инвестиция программасы проектын карау нәтиҗәләре буенча Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт органнары һәм оешмалары бәяләмәләрен җыя һәм карый һәм, инвестиция программасы проектына карата кисәтүләр һәм тәкъдимнәр булмаганда, инвестиция программасын раслау турында карар проектын әзерләүне гамәлгә ашыра.

Бүлек белгече кисәтүләрне һәм (яки) инвестиция программасы проектын карау нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне алган көннән соң 5 эш көне эчендә аларны, күрсәтелгән кисәтүләр һәм (яки) бәяләмәләр Кагыйдәләрнең 49 һәм 50 пунктларында билгеләнгән срокларда килү шарты белән, мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Бүлек инвестиция программасы проектын карауга алу турында хәбәр урнаштырылган көннән башлап 35 календарь көненнән (25 календарь көненнән, – Кагыйдәләрнең 67 пунктындагы икенче абзацында каралган очраклар өчен; 10 календарь көненнән, – Кагыйдәләрнең 69 пунктында каралган очрак өчен) соңга калмыйча, инвестиция программасы проектына карата Кагыйдәләрнең 49 һәм 50 пунктларында каралган инвестиция программасы проектына бәяләмәләрне карауны исәпкә алып әзерләнгән кисәтүләрен мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында инвестиция программасы проектын карауга

кабул итү турында хәбәр урнаштырылган көннән башлап 35 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе булып түбәндәге гамәлләрнең берсе тора:

мөрәҗәгать итүчегә инвестиция программасы проектына кисәтүләр җибәрү;

Бүлек белгеченә инвестиция программасын раслау турында карар проектын әзерләргә кушу.

Әлеге административ процедура составына керүче административ гамәлләрне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып әлеге Регламентта әлеге мондый административ гамәлләрне башкаручы затлар буларак билгеләнгән вазыйфаи затлар тора.

3.6. Эшләнеп беткән инвестиция программасы проекты турында хәбәрне кабул итү, теркәү һәм карау.

3.6.1. Министрлыкка мөрәҗәгать итүчедән эшләнеп беткән инвестиция программасы проекты һәм аңа теркәп бирелә торган материаллар керү административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүче – электр энергетикасы субъекты, мөрәҗәгать итүче – челтәр оешмасыннан тыш, Министрлык тарафыннан инвестиция программасы проектын карауга алу турында хәбәр урнаштырылган көннән башлап 65 календарь көненнән (35 календарь көненнән, – Кагыйдәләрнең 67 пунктындагы икенче абзацында каралган очраклар өчен) соңга калмыйча дәүләт хакимияте органнары һәм инвестиция программасын карауда катнаша торган оешмаларның кисәтүләрен исәпкә алып, өстәмә эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын урнаштыра һәм урнаштырган көннән соңга калмыйча Министрлыкка өстәмә эшләп бетерлгән инвестиция программасы проекты турында хәбәрне, әлеге Административ регламентның 2.5.1.2 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларның кисәтүләрен исәпкә алып өстәмә эшләнеп беткән мәгълүматны һәм өстәмә эшләнгән инвестиция программасы проектында күрсәтелгән кисәтүләрне исәпкә алу турында яки мондый кисәтүләрне исәпкә алудан нигезле баш тарту турында мәгълүматны үз эченә алган аңлатма язуын җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче – челтәр оешмасы Министрлык тарафыннан инвестиция программасы проектын карауга алу турында хәбәр урнаштырылган көннән башлап 85 календарь көненнән (35 календарь көненнән, – Кагыйдәләрнең 67 пунктындагы икенче абзацында каралган очраклар өчен; 20 календарь көненнән, – Кагыйдәләрнең 69 пунктында каралган очрак өчен) соңга калмыйча дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларның кисәтүләрен исәпкә алып өстәмә эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын, инвестиция программасы проектын эшләп бетерү буенча Тармакара кулланучылар советы тәкъдимнәрен исәпкә алу турында яки аларны исәпкә алудан нигезле баш тарту турында мәгълүматны үз эченә алган аңлатма язуын, шулай ук булганда – өстәмә эшләп бетерлгән инвестиция программасы проектына технологик һәм бәя аудитын уздыру нәтиҗәләре буенча бәяләмәне урнаштыра һәм урнаштыру көненнән соңга калмыйча Министрлыкка өстәмә

эшләп бетерлгән инвестиция программасы проекты турында хәбәрне, өстәмә эшләп бетерлгән инвестиция программасы проектында күрсәтелгән кисәтүләрне исәпкә алу турында яки мондый кисәтүләрне исәпкә алудан нигезле баш тарту турында мәгълүматны үз эченә алган мәгълүматны җибәрә.

3.6.2. Министрлыкның эш башкару һәм контроль бүлеге белгече эшләнеп беткән инвестиция проекты турында килгән хәбәрне билгеләнгән тәртиптә теркәүне гамәлгә ашыра.

3.6.3. Эшләнеп беткән инвестиция проекты турында килгән хәбәр теркәлгәннән соң министр гаризаны карый, башкаручыларны билгели һәм министрның тикшерүдә тотучы урынбасары аша гаризаны Бүлеккә җибәрә.

3.6.4. Бүлек белгече эшләнеп беткән инвестиция программасы турында хәбәр килгән көннән башлап 5 эш көне узганчы мөрәҗәгать итүчегә мондый хәбәрне һәм эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын караудан баш тарту турында, тулы холыклы кисәтүләрне күрсәтеп, нигезләнгән хат җибәрә, түбәндәге очракларда:

а) эшләнеп беткән инвестиция программасы проекты турында мәгълүмат системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында тулы күләмендә урнаштырылмаган һәм (яки) аның электрон документларын ачу форматларына карата билгеләнгән таләпләрне бозып һәм (яки) билгеләнмәгән форма буенча урнаштырылган очракта;

б) өстәмә эшләнеп беткән инвестиция программасы проекты турында мәгълүматта һәм аны нигезли торган материалларда һәм (яки) өстәмә эшләнеп беткән инвестиция программасы проекты турында хәбәрдә һәм (яки) аңа теркәлә торган материалларда төгәл булмаган белешмәләр булганда;

в) эшләнеп беткән инвестиция программасына теркәлә торган, әлеге Регламентның 3.6.1 пунктында күрсәтелгән материалларны тулы күләмдә һәм (яисә) аларның электрон документлар форматына карата билгеләнгән таләпләрне бозып һәм (яки) билгеләнмәгән форма буенча тапшырганда;

г) электр энергетикасы субъектының өстәмә эшләнгән инвестиция программасы проектын тормышка ашыру чоры Кагыйдәләрнең 3 пунктында күрсәтелгән чорга һәм (яки) гаризада күрсәтелгән инвестиция программасы проектын тормышка ашыру чорына туры килмәгәндә.

3.6.5. Мөрәҗәгать итүче эшләнеп беткән инвестиция программасы турында хәбәрне һәм аңа теркәлә торган документларны Министрлык кисәтүләрен бетергәннән соң, ләкин Министрлык тарафыннан мондый кисәтүләр мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән көннән соң 5 эш көне узганчы, эшләнеп беткән инвестиция программасы проекты турында мәгълүмат ачылган көннән соңга калмыйча Министрлыкка җибәрә.

3.6.6. Бүлек белгече эшләнеп беткән инвестиция программасы турында хәбәр һәм аңа теркәп бирелә торган материаллар алынганнан соң 5 эш көне эчендә системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәр урнаштыра, шулай ук мондый хәбәрне мөрәҗәгать итүчегә дә җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

эшләнеп беткән инвестиция программасы проекты турында хәбәрне теркәү – хәбәр кергәннән соң бер эш көне эчендә;

эшләнеп беткән инвестиция программасы проекты турында хәбәрне карау һәм мөрәҗәгать итүчегә хәбәрне караудан баш тарту турында яки эшләнеп беткән инвестиция проектын карауга кабул итү турында хәбәр җибәрү – мондый хәбәр кергән көннән алып 5 эш көне эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе булып түбәндәге гамәлләрнең берсе тора:

эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәрне системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында урнаштыру һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрү;

мөрәҗәгать итүчегә эшләнеп беткән инвестиция программасы проекты турында хәбәрне һәм эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын караудан баш тарту турында хат җибәрү.

Әлеге административ процедура составына керүче административ гамәлләрне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып әлеге Регламентта әлеге мондый административ гамәлләрне башкаручы затлар буларак билгеләнгән вазыйфаи затлар тора.

3.7. Эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәрне үз эченә алган ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм дәүләт органнарына һәм оешмаларга җибәрү.

3.7.1. Административ процедураны башлау өчен эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауга алу турында хәбәрне системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында урнаштыру нигез булып тора.

3.7.2. Бүлек белгече, эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәр системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында урнаштырылган көннән соңга калмыйча, мондый хәбәрне, шулай ук эшләнеп беткән инвестиция программасына теркәлә торган, Министрлыкка килгән материалларны әлеге Регламентның 3.4.2 пунктындагы а-в пунктчаларында күрсәтелгән дәүләт органнарына һәм оешмаларына һәм, челтәр оешмасының эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәр җибәрелгән булса, Тармакара кулланучылар советына җибәрә (Кагыйдәләрнең 67 пунктындагы икенче абзацта һәм 69 пунктта каралган очракларда күрсәтелгән хәбәр җибәрелми).

3.7.3. Әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт органнары һәм оешмалар эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә карый һәм Кагыйдәләрнең 55, 56 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм срокларга туры китереп, эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карау нәтиҗәләре буенча кисәтүләрне һәм (яисә) бәяләмәне Министрлыкка тапшыра.

Әлеге пунктчаларда билгеләнә торган процедуралар системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәр урнаштырылган көннән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт органнарына һәм оешмаларына җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

Әлеге административ процедура составына керүче административ гамәлләрне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып әлеге Регламентта әлеге мондый административ гамәлләрне башкаручы затлар буларак билгеләнгән вазыйфаи затлар тора.

3.8. Эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карау.

3.8.1. Административ процедураны башлау өчен эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауга алу турында хәбәрне системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында урнаштыру нигез булып тора.

3.8.2. Бүлек белгече Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауны гамәлгә ашыра.

3.8.3. Эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карау нәтиҗәләре буенча Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт органнары һәм оешмалары бәяләмәләрен җыя һәм карый һәм, эшләнеп беткән инвестиция программасы проектына карата кисәтүләр һәм тәкъдимнәр булмаганда, инвестиция программасын раслау турында карар проектын әзерләүне гамәлгә ашыра.

Бүлек белгече кисәтүләрне һәм (яки) инвестиция программасы проектын карау нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне алган көннән соң 5 эш көне эчендә аларны, күрсәтелгән кисәтүләр һәм (яки) бәяләмәләр Кагыйдәләрнең 55 пунктында билгеләнгән срокларда килү шарты белән, мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Бүлек белгече эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауга алу турында хәбәр урнаштырылган көннән башлап 25 календарь көненнән (20 календарь көненнән, – әлеге Кагыйдәләрнең 67 пунктындагы икенче абзацында каралган очраклар өчен; 10 календарь көненнән, – әлеге Кагыйдәләрнең 69 пунктында каралган очрак өчен) соңга калмыйча, эшләнеп беткән инвестиция программасы проектына карата Кагыйдәләрнең 55 һәм 56 пунктларында каралган эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карау нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне карауны исәпкә алып әзерләнгән кисәтүләрен мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәр урнаштырылган көннән башлап 25 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе булып түбәндәге гамәлләрнең берсе тора:

мөрәҗәгать итүчегә эшләнеп беткән инвестиция программасы проектына кисәтүләр җибәрү;

Бүлек белгеченә инвестиция программасын раслау турында карар проектын әзерләргә кушу.

Әлеге административ процедура составына керүче административ гамәлләрне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып әлеге Регламентта әлеге

мондый административ гамәлләрне башкаручы затлар буларак билгеләнгән вазыйфаи затлар тора.

3.9. Килештерү киңәшмәләрен үткәрү.

3.9.1. Мөрәҗәгать итүчегә эшләнеп беткән инвестиция программасы проектына искәрмәләр җибәрү административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

3.9.2. Эшләнеп беткән инвестиция программасы проектына карата Россия Энергетика министрлыгы кисәтүләре булган очракта, Министрлык Кагыйдәләрнең 58 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле вәкилләре, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы, киңәшмәдә каралачак кисәтүләр аларның эшчәнлек өлкәсенә карый торган оешмаларның вәкаләтле вәкилләре катнашында уздыра торган килештерү киңәшмәсендә катнаша.

Россия Энергетика министрлыгы үткәргән килештерү киңәшмәсе нәтиҗәләре буенча килештерү киңәшмәсе беркетмәсе төзелә. Министр яки Бүлек эшчәнлеген алып баручы министр урынбасары килештерү киңәшмәсе беркетмәсе кергән көннән алып 5 эш көне эчендә аңа кул куя.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә Россия Энергетика министрлыгы белән килештерү киңәшмәсе беркетмәсен аңа имза куелганнан соң җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

Россия Энергетика министрлыгына эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәр алынган көннән алып 60 календарь көннән дә соңга калмыйча Россия Энергетика министрлыгының килештерү киңәшмәләрендә катнашу;

Россия Энергетика министрлыгының килештерү киңәшмәсе беркетмәсен имзалау һәм җибәрү – мондый беркетмә кергән көннән соң 5 эш көне эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә Россия Энергетика министрлыгының килештерү киңәшмәсе беркетмәсен җибәрү.

3.9.3. Әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт органнары һәм оешмалары кисәтүләре булган очракта, Бүлек эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауга алу турында хәбәр урнаштырылган көннән башлап 45 календарь көне узганчы (Кагыйдәләрнең 67 пунктындагы икенче абзацында каралган очраклар өчен – 25 календарь көне узганчы; Кагыйдәләрнең 69 пунктында каралган очрак өчен – 15 календарь көне узганчы) мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле вәкилләре, күрсәтелгән кисәтүләрне Министрлыкка җибәргән Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты, Урта Идел БДБ вәкилләре катнашында килештерү киңәшмәләре уздыра.

Министрлыкның килештерү киңәшмәсе беркетмәсендә инвестиция программасы проекты буенча ризасызлыкларга карата кабул ителгән карарлар, шул исәптән инвестиция программасы проекты буенча җайга салынмаган ризасызлыклар, инвестиция программасы проектын алар буенча инвестиция программасы проекты буенча ризасызлыклар җайга салынган кисәтүләрне исәпкә алуга кагылышлы өлешендә эшләп бетерү буенча килештерелгән карарлар, эшләп бетерү срогын күрсәтеп, шулай ук инвестиция программасы проектын алар буенча инвестиция программасы проекты буенча ризасызлыклар

җайга салынмыйча калган кисәтүләр өлешендә эшләр бетерү буенча Министрлык тәкъдимнәре чагылдырыла.

Кагыйдәләрнең 67 пунктындагы икенче абзацында һәм 69 пунктында каралган очраклар өчен килештерү киңәшмәсе беркетмәсендә инвестиция программасына үзгәрешләр (инвестиция программасына төзәтмәләр) проектын эшләп бетерү турында, эшләп бетерү срокларын күрсәтеп, кабул ителгән Министрлык карарлары чагылдырыла.

Килештерү киңәшмәләренең беркетмәләре Бүлек белгече тарафыннан төзелә һәм министр (яки министр күрсәтмәсе буенча аның урынбасары) тарафыннан, шулай ук тиешле башкарма хакимият органы (оешма) җитәкчесе (аның күрсәтмәсе буенча җитәкче урынбасары) тарафыннан мондый килештерү киңәшмәсе беркетмәсе тиешле башкарма хакимият органына (оешмага) кергән көннән алып 5 эш көне эчендә кул куела.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, кул куелганнан соң, килештерү киңәшмәләре беркетмәләрен җибәрә, ә килешү киңәшмәсенең имзаланган беркетмәсе Министрлыкка килмәгән очракта – кул кую өчен тиешле башкарма хакимият органына (оешмага) кергән көненнән соң 5 эш көне узгач.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауга кабул итү турында хәбәр урнаштырылган көннән алып 45 календарь көннән соңга калмыйча Министрлыкның килештерү киңәшмәләрен уздыру;

Министрлыкның килештерү киңәшмәләре беркетмәләрен имзалау һәм аларны мөрәҗәгать итүчегә җибәрү – аларга кул куелган көннән алып 5 эш көне эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә Министрлыкның килештерү киңәшмәләре беркетмәләрен җибәрү.

Әлеге административ процедура составына керүче административ гамәлләрне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып әлеге Регламентта әлеге мондый административ гамәлләрне башкаручы затлар буларак билгеләнгән вазыйфаи затлар тора.

3.10. Җайга салынмаган каршылыкларны карау.

3.10.1. Әлеге Регламентның 3.9 пункты нигезендә инвестиция программасы проекты буенча җайга салынмаган каршылыкларны үз эченә алган килештерү киңәшмәләре беркетмәләрен мөрәҗәгать итүчегә җибәрү административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

3.10.2. Инвестиция программасы проекты буенча әлеге Регламетның 3.9 пунктында каралган җайга салынмаган ризасызлыклар булганда, Бүлек тиешле килештерү киңәшмәләре беркетмәләрен үз эченә алган инвестиция программасы проекты буенча җайга салынмаган ризасызлыкларны карау турында мөрәҗәгатьне, инвестиция программасы проекты буенча ризасызлыклар материалларын һәм инвестиция программасы проектын урнаштыру урыны (тулы электрон адресын) турында мәгълүматны килештерү киңәшмәләре беркетмәләре имзаланганнан соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә, ә килештерү киңәшмәсенең имзаланган беркетмәсе Министрлыкка килмәгәндә –

дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы тиешле дәүләт хакимияте органына (оешмага) имза кую өчен килгән көненнән башлап 5 эш көне узгач.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге пунктта каралган мөрәҗәгать җибәрелгән көннән дә соңга калмыйча, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә инвестиция программасы проекты буенча җайга салынмаган каршылыклар турында хәбәр җибәрә, анда күрсәтелгән мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелгән дата күрсәтелергә тиеш.

Җайга салынмаган каршылыкларны карау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

Бүлек белгече әлеге пунктчада каралган җайга салынмаган каршылыкларны карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары алынган көннән соң 5 эш көне эчендә аны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

килештерү киңәшмәләре беркетмәләренә кул куйганнан соң 1 эш көне дәвамында җайга салынмаган каршылыклар турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына мөрәҗәгать җибәрү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителгәннән соң 5 эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә җайга салынмаган каршылыкларга карата Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын җибәрү.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җайга салынмаган каршылыкларга карата Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын җибәрү.

3.10.3. Челтәр оешмасы эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын урнаштырган очракта, анда инвестиция программасы проекты буенча иҗтимагый фикер алышу барышында системаның рәсми сайтында урнаштырылган тәкъдимнәр һәм инвестиция программасы проектын эшләп бетерү буенча әлеге Кагыйдәләр нигезендә системаның рәсми сайтында урнаштырылган Тармакара кулланучылар советы тәкъдимнәре исәпкә алынмаса, Тармакара кулланучылар советы өчен Кагыйдәләрнең 61 пунктында челтәр оешмасы тарафыннан системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында урнаштырылган инвестиция программасы проекты буенча иҗтимагый фикер алышу барышында килгән, күрсәтелгән тәкъдимнәрнең берсен яки берничәсен, күрсәтелгән тәкъдимнәр буенча материалларны, тәкъдимнәр җыелмасын исәпкә алу зарурилыгы турында мөрәҗәгатьне һәм (яки) системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында урнаштырылган инвестиция программасы проектын эшләп бетерү буенча Тармакара кулланучылар советы тәкъдимнәре күчермәсен Тармакара кулланучылар советы әгъзалары катнашында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында карау һәм күрсәтелгән тәкъдимнәр буенча тиешле карарлар кабул итү өчен челтәр оешмасының эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карауга алу турында хәбәр Министрлык тарафыннан урнаштырылган көннән башлап 20 календарь көне эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрү хокукы күздә тотыла.

Регламентның әлеге пунктчасында каралган Тармакара кулланучылар советы мөрәҗәгатен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан карау законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

Бүлек белгече әлеге мөрәҗәгатьне карап тикшерү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары алынган көннән соң 5 эш көне эчендә аны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә, шулай ук системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының күрсәтелгән карары турында мәгълүмат урнаштыра.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла: Тармакара кулланучылар советы кисәтүләренә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителгән көннән алып 5 эш көне эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә Тармакара кулланучылар советы кисәтүләренә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын җибәрү.

Әлеге административ процедура составына керүче административ гамәлләрне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып әлеге Регламентта әлеге мондый административ гамәлләрне башкаручы затлар буларак билгеләнгән вазыйфаи затлар тора.

3.11. Ахыргы инвестиция программасы проекты турында хәбәрне кабул итү, теркәү һәм карау.

3.11.1. Министрлыкка мөрәҗәгать итүчедән ахыргы инвестиция программасы һәм аңа теркәп бирелә торган материаллар керү административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 3.9 пунктында каралган, килештерү киңәшмәләре беркетмәләрендә булган инвестиция программасы проектын эшләп бетерү буенча килештерелгән карарларга туры китереп эшләнеп беткән инвестиция программасының ахыргы проектын килештерү киңәшмәләренең күрсәтелгән беркетмәләрендәге иң соңгы срокларында системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында Стандартларга туры китереп урнаштыра, ә килештерү киңәшмәләре беркетмәләрендә электр энергиясе субъекты тарафыннан эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын урнаштыруның конкрет сроклары булмаганда, – килештерү киңәшмәләренең күрсәтелгән беркетмәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан алынган көннән башлап 15 календарь көне узмаган срокта.

Министрлык тарафыннан инвестиция программасы проекты буенча җайга салынмаган ризасызлыкларның булуы һәм (яки) әлеге Регламентның 3.10.3 пунктында каралган Тармакара кулланучылар советы мөрәҗәгате булуы турында хәбәр җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 3.9, 3.10 пунктларында каралган, килештерү киңәшмәләре беркетмәләрендә булган инвестиция программасы проектын эшләп бетерү буенча килештерелгән караралар һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары (мөрәҗәгать итүче мондый карарларны гариза Министрлыкка җибәрелгән елның 30 сентябренә кадәр алган шарт белән) нигезендә эшләнеп беткән инвестиция

программасы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларында күрсәтелгән срокларның иң соңгысында системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында урнаштыра, ә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарарында электр энергиясе субъекты тарафыннан инвестиция программасының ахыргы проектын урнаштыру буенча конкрет сроклар булмаганда - мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының күрсәтелгән карарлары алынган көннән соң 15 календарь көне узмаган срокта.

Әлеге бүлектә каралган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары алынмаган очракта, Министрлыкка гариза җибәрелгән елның 30 сентябренә кадәр, электр энергетикасы субъекты күрсәтелгән елның 15 октябреннән соңга калмыйча системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә әлеге Регламентның 3.9 пунктында каралган Россия Энергетика министрлыгы һәм Министрлык тәкъдимнәре, Министрлык карарлары һәм килештерү киңәшмәләре беркетмәләрендә күрсәтелгән инвестиция программасы проектын эшләп бетерү буенча килешенгән карарлар нигезендә эшләнеп беткән инвестиция программасының ахыргы проектын урнаштыра, шулай ук Кагыйдәләрнең 70 пункты нигезендә мондый инвестиция программасына (инвестиция программасына төзәтмәләр) үзгәрешләр проектын да урнаштыра.

Мөрәҗәгать итүче системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында инвестиция программасының ахыргы проекты урнаштырылган көннән соңга калмыйча Министрлыкка ахыргы инвестиция программасы турында хәбәр һәм әлеге пунктта күрсәтелгән карарларның, шулай ук Россия Энергетика министрлыгы һәм Министрлык тәкъдимнәренең ахыргы проектта исәпкә алынуы турында мәгълүмат булган аңлатма язуы җибәрә.

Электр энергетикасы субъектлары, челтәр оешмаларыннан тыш, ахыргы инвестиция программасы турында хәбәр белән бергә, әлеге пунктта күрсәтелгән карарлар, шулай ук Россия Энергетика министрлыгы һәм Министрлык тәкъдимнәре нигезендә эшләнеп беткән әлеге Регламентның 2.5.1.2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны да җибәрә.

3.11.2. Министрлыкның эш башкару һәм контроль бүлеге белгече ахыргы инвестиция проекты турында килгән хәбәрне билгеләнгән тәртиптә теркәүне гамәлгә ашыра.

3.11.3. Ахыргы инвестиция проекты турында килгән хәбәр теркәлгәннән соң министр гаризаны карый, башкаручыларны билгели һәм министрның тикшерүдә тотучы урынбасары аша гаризаны Бүлеккә җибәрә.

3.11.4. Бүлек белгече ахыргы инвестиция программасы турында хәбәр килгән көннән башлап 5 эш көне узганчы мөрәҗәгать итүчегә мондый хәбәрне һәм ахыргы инвестиция программасы проектын караудан баш тарту турында, тулы холыклы кисәтүләрне күрсәтеп, системаның (Министрлыкның) рәсми сайтыннан файдаланып, нигезләнгән хат җибәрә, түбәндәге очракларда:

а) ахыргы инвестиция программасы проекты турында мәгълүмат системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында тулы күләмендә урнаштырылмаган һәм (яки) аның электрон документларын ачу форматларына

карата билгеләнгән таләпләрне бозып һәм (яки) билгеләнмәгән форма буенча урнаштырылган очракта;

б) инвестиция программасының ахыргы проекты турында мәгълүматта һәм аны нигезли торган материалларда һәм (яки) инвестиция программасының ахыргы проекты турында хәбәрдә һәм (яки) аңа теркәлә торган материалларда төгәл булмаган белешмәләр булганда;

в) ахыргы инвестиция программасына теркәлә торган, әлеге Регламентның 3.11.1 пунктчасында күрсәтелгән материалларны тулы күләмдә һәм (яисә) аларның электрон документлар форматына карата билгеләнгән таләпләрне бозып һәм (яки) билгеләнмәгән форма буенча тапшырганда;

г) ахыргы инвестиция программасы турында хәбәрдә күрсәтелгән адрес буенча «Интернет» челтәрендә урнаштырылган ахыргы инвестиция программасы проектын тормышка ашыру чоры электр энергетикасы субъектының инвестиция программасын тормышка ашыруга карата Кагыйдәләрнең 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә һәм (яки) гаризада күрсәтелгән адрес буенча «Интернет» челтәрендә урнаштырылган инвестиция программасы проектын гамәлгә ашыру чорына туры килмәгәндә;

д) Министрлыкка ахыргы инвестиция программасы турында хәбәр килгән очракта, әгәр ахыргы инвестиция программасы проектында әлеге Регламентның 3.11.1 пунктчасында күрсәтелгән Россия Энергетика министрлыгының һәм (яки) Министрлыкның тәкъдимнәре һәм (яисә) карарлары исәпкә алынмаган булса һәм (яки) ахыргы инвестиция программасы проектында әлеге Регламентның 3.11.1 пунктчасында күрсәтелгән Россия Энергетика министрлыгы һәм (яки) Министрлык тәкъдимнәрендә һәм (яисә) карарларынла каралмаган үзгәрешләр булса;

е) Министрлыкка ахыргы инвестиция программасы турында хәбәр килгәндә, әгәр ахыргы инвестиция программасы проекты Кагыйдәләрнең 5 пунктында күрсәтелгән инвестиция программасын раслау шартларына туры килмәсә.

3.11.5. Мөрәҗәгать итүче ахыргы инвестиция программасы турында хәбәрне һәм аңа теркәлә торган документларны Министрлык кисәтүләрен бетергәннән соң, ләкин Министрлык тарафыннан мондый кисәтүләр электр энергетикасы субъектына җибәрелгән көннән соң 5 эш көне узганчы, ахыргы инвестиция программасы проекты турында мәгълүмат ачылган көннән соңга калмыйча, системаның (Министрлыкның) рәсми сайтыннан файдаланып, Министрлыкка җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

ахыргы инвестиция программасы проекты турында хәбәрне теркәү – хәбәр кергәннән соң бер эш көне эчендә;

инвестиция программасының ахыргы проекты турында хәбәрне карау һәм мөрәҗәгать итүчегә мондый хәбәрне карап тикшерүдән баш тарту турында хат җибәрү – мондый хәбәр килгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе булып түбәндәге гамәлләрнең берсе тора:

а) мөрәҗәгать итүчегә инвестиция программасының ахыргы проекты турында хәбәрне караудан баш тарту турында хат җибәрү;

б) инвестиция программасын раслаудан нигезле баш тарту әзерләү турында йөкләмә;

в) инвестиция программасын раслау турында карар әзерләү турында йөкләмә.

Әлеге административ процедура составына керүче административ гамәлләрне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып әлеге Регламентта әлеге мондый административ гамәлләрне башкаручы затлар буларак билгеләнгән вазыйфаи затлар тора.

3.12. Инвестиция программасын раслаудан дәлилле баш тартуны әзерләү.

3.12.1. Административ процедураны башлап җибәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) үзенә карата гариза җибәрелгән инвестиция программасы проектын карауга алу турында хәбәр системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында урнаштырганнан соң һәм (яки) мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгәннән соң гаризаны кире алу (гамәлдән чыгару) турында мөрәҗәгать итүчедән таләп алу;

б) эшләнеп беткән инвестиция программасы турында хәбәрнең яки ахыргы инвестиция программасы турында хәбәрнең эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын урнаштыру һәм эшләнеп беткән инвестиция программасы турында Министрлыкка хәбәр җибәрү яки инвестиция программасының ахыргы проектын урнаштыру һәм Министрлыкка ахыргы инвестиция программасы проекты турында хәбәр җибәрүнең Кагыйдәләрнең 52-54, 62 һәм 62.1 пунктларында күрсәтелгән сроклары узган көннән соң 10 календарь көнендә килмәве;

в) ахыргы инвестиция программасы проекты турында хәбәрне кабул итү, теркәү һәм карау буенча административ процедураны төгәлләү нәтиҗәләре буенча сәбәпләрен күрсәтеп, инвестиция программасын раслаудан нигезле баш тарту проектын әзерләү турында йөкләмә бирелү.

3.12.2. Бүлек мөрәҗәгать итүчегә инвестиция программасын раслаудан баш тарту турында нигезләнгән хат җибәрә, шулай ук әлеге Регламентның 3.4.2 пунктындагы а-в пунктчаларында күрсәтелгән дәүләт органнарына һәм оешмаларга җибәрә, әгәр инвестиция программасын раслаудан баш тарту турында нигезле хат челтәр оешмасына җибәрелсә, Тармакара кулланучылар советына тиешле хәбәрне җибәрә (күрсәтелгән хәбәр Кагыйдәләрнең 67 пунктының икенче абзацында һәм 69 пунктында каралган очракларда җибәрелми), түбәндәге очракларда:

а) мөрәҗәгать итүчедән гаризаны кайтарып алу (гамәлдән чыгару) турында рәсми мөрәҗәгать алынганда;

б) эшләнеп беткән инвестиция программасы турында хәбәр яки ахыргы инвестиция программасы турында хәбәр Кагыйдәләрнең 52-54, 62 һәм 62(1) пунктларында күрсәтелгән сроклар узган көннән соң 10 календарь көне эчендә килмәгәндә;

в) Кагыйдәләрнең 62(1) пунктындагы икенче-җиденче абзацларда күрсәтелгән, әгәр Министрлык Кагыйдәләрнең 62(1) пункты нигезендә ахыргы инвестиция программасы турында хәбәрне һәм тиешле ахыргы инвестиция

программасын караудан баш тарту турында хатны мөрәҗәгать итүчегә җибәргән булса.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар шушы пунктның 3.12.1 пунктчасында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 5 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе булып түбәндәге тора:

мөрәҗәгать итүчегә инвестиция программасын раслаудан Министрлыкның баш тарту турында хат җибәрү;

әлеге Регламентның 3.4.2 пунктындагы а-в пунктчаларында күрсәтелгән дәүләт органнарына һәм оешмаларга инвестиция программасын раслау турында хәбәр җибәрү, әгәр инвестиция программасын раслаудан дәлилле баш тарту турында хат челтәр оешмасына җибәрелсә.

Әлеге административ процедура составына керүче административ гамәлләрне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып әлеге Регламентта әлеге мондый административ гамәлләрне башкаручы затлар буларак билгеләнгән вазыйфаи затлар тора.

3.13. Инвестиция программасын раслау һәм мөрәҗәгать итүчегә тиешле карар җибәрү турында карар әзерләү.

3.13.1. Бүлеккә түбәндәге административ процедураларның берсен тәмамлау нәтиҗәләре буенча инвестиция программасын раслау турында карар проектын әзерләүне тәэмин итү йөкләмәсе административ процедураны башлау өчен нигез булып тора:

а) инвестиция программасы проектын карау;

б) эшләнеп беткән инвестиция программасы проектын карау;

в) ахыргы инвестиция программасы проекты турында хәбәрне кабул итү, теркәү һәм карау.

3.13.2. Алдагы чорларда инвестиция программаларын тормышка ашыруны тикшерүдә тоту нәтиҗәләрен исәпкә алып (алдагы чорларда инвестиция программалары тормышка ашырылганда), инвестиция программасы проектына карата Кагыйдәләрнең 49, 50 һәм 55 пунктларында каралган кисәтүләр һәм тәкъдимнәр булмаганда, тиешле гариза Министрлыкка җибәрелгән елның 1 ноябренә кадәр Министрлык инвестиция программасын раслый, ә Кагыйдәләрнең 58-61 пунктларында каралган очракларда, – электр энергетикасы субъекты тарафыннан системаның рәсми сайтында Кагыйдәләрнең 62 пункты нигезендә инвестиция программасының ахыргы проекты урнаштырылганнан соң 15 эш көне эчендә.

Федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары нигезендә мондый бәяләмәләрне (хисапларны) алу мәҗбүри булып торган очракларда, технологик һәм бәя аудитын уздыру нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр (хисаплар) булганда, Министрлык инвестиция программасын раслый.

3.13.3. Инвестиция программасын раслау турында карар Бүлек белгече тарафыннан Министрлык боерыгы рәвешендә төзелә, ул министр (аның

вазыйфаларын башкаручы зат) кул куя торган электрон документ рәвешендә ясала.

3.13.4. Министрлык системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында инвестиция программасын раслау турында карарны Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы һәм Монополиягә каршы федераль хезмәт белән килештереп, Россия Энергетика министрлыгы раслаган форма буенча кабул иткән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштыра.

Системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында инвестиция программасын раслау турында карар урнаштырылган көннән дә соңга калмыйча Министрлык тиешле хәбәрне мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар шушы пунктның 3.13.1 пунктчасында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач 20 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: инвестиция программасын раслау турында караны системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында урнаштыру турында хәбәрне системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында урнаштыру һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрү.

Әлеге административ процедура составына керүче административ гамәлләрне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып әлеге Регламентта әлеге мондый административ гамәлләрне башкаручы затлар буларак билгеләнгән вазыйфаи затлар тора.

3.14. расланган инвестиция программасына үзгәрешләр кертү.

3.14.1. Инвестиция программасына үзгәрешләр кертү (инвестиция программасына төзәтмәләр кертү) зарурлыгы булган очракта, күрсәтелгән үзгәрешләр Министрлык тарафыннан расланырга тиеш. Инвестиция программасына үзгәрешләрне раслау әлеге Регламентта билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла, әлеге пунктның икенче абзацында каралган очраклардан тыш.

Инвестиция программасына әлеге Регламент күздә тоткан федераль законнарны (Татарстан Республикасы законнарын), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын үтәү максатында кертелә торган үзгәрешләр (инвестиция программасына төзәтмәләр), шулай ук инвестиция программасына аварияле хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерү яки аны булдырмау зарурлыгы булган очракта кертелә торган үзгәрешләр (инвестиция программасына төзәтмәләр) Министрлык тарафыннан мондый үзгәрешләр хакында иҗтимагый фикер алышуларны уздырмыйча, технологик һәм бәя аудитын уздырмыйча һәм әлеге Регламентта каралган килешүләрне һәм әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт органнарыннан һәм оешмалардан бәяләмәләр алмыйча раслана.

Инвестиция программасына кертелә торган үзгәрешләр инвестиция программасын гамәлгә ашырган агымдагы елның һәм инвестиция программасын тормышка ашыру елларының Министрлыкка гариза җибәргән датага килеп җитмәгән өлешендә (раслана торган үзгәрешләрдә инвестиция программасын

тормышка ашыру чорын озынайтуның Кагыйдәләрнең 68 пунктындагы икенче абзацта күрсәтелгән срогын исәпкә алып) раслана.

Агымдагы елда Министрлык тарафыннан планлаштыруның киләсе чорына инвестиция программасын һәм Министрлык тарафыннан раслана торган инвестиция программасына кертелә торган үзгәрешләрне раслау максатларында, Кагыйдәләрнең 69 һәм 70 пунктларында күрсәтелгән очраклардан тыш, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка инвестиция программасы проектына һәм инвестиция программасына кертелә торган үзгәрешләр проектына карата әлеге Регламентның 2.5.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны үз эченә алган бер гариза җибәрелә.

3.14.2. Инвестиция программасын тормышка ашыра башлау елы үзгәртелергә тиеш түгел.

Продукциясенә (хезмәтенә) бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу җайга салуның озак сроклы параметрлары нигезендә гамәлгә ашырылучы электр энергетикасы субъектына карата җайга салуның озак сроклы чорының гамәлдә булу срогын арттыру максатларында инвестиция программасына үзгәрешләр (инвестиция программасына төзәтмәләр) кертелгәндә мондый инвестиция программасын тормышка ашыру чоры җайга салуның озак сроклы чорын озынайтуның гамәлдә булу срогының планлаштырылган тиешле озынлыгына озынайтылырга мөмкин.

3.14.3. Мөрәҗәгать итүче – челтәр оешмасының инвестиция программасы әлеге Регламент нигезендә территориаль планлаштыру документларын раслаганчыга кадәр расланган булса һәм территориаль планлаштыру документларында чагылдырылырга тиешле, ләкин территориаль планлаштыруның күрсәтелгән документларында каралмаган федераль әһәмияттәге объектларны, төбәк әһәмиятендәге объектларны, җирле әһәмияттәге объектларны оештыруны күздә тотса, мөрәҗәгать итүче – челтәр оешмасы территориаль планлаштыруның тиешле документын раслау турында вәкаләтле дәүләт хакимияте органы карары рәсми басылып чыккан көннән соң 15 календарь көне узганчы системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп мондый инвестиция программасына күрсәтелгән объектларны төшереп калдыруны күздә тотучы үзгәрешләр (инвестиция программасына төзәтмәләр) проектын урнаштыра һәм Министрлыкка гариза җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче – челтәр оешмасының инвестиция программасына әлеге пунктта каралган үзгәрешләр (инвестиция программасына төзәтмәләр) мондый үзгәрешләр хакында иҗтимагый фикер алышуларны уздырмыйча, шулай ук башкарма хакимият органнары һәм әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән оешмалар белән килештермичә шәһәр төзү эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән срокта раслана.

3.14.4. Әгәр Министрлык тарафыннан әлеге Регламентта карлаган очракларда аның ахыргы проектын әзерәгәндә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары исәпкә алынмаган инвестиция программасы (инвестиция программасына кертелә торган үзгәрешләр) расланган булса, электр энергетикасы субъекты Бердәм порталда мондый инвестиция программасына

кертелә торган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының күрсәтелгән карары нигезендә әзерләнгән үзгәрешләрне (инвестиция программасына төзәтмәләрне) мондый карарда билгеләнгән срокта урнаштыра, ә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында электр энергетикасы субъекты тарафыннан системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында инвестиция программасы проектын урнаштыруның конкрет срогы булмаганда – электр энергетикасы субъекты тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының әлеге карары алынган көннән башлап 15 календарь көне узганчы, ләкин системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында инвестиция программасын раслау турында карар урнаштыру турында Министрлык хәбәрен алган көннән иртәрәк булмаган срокта.

Мөрәҗәгать итүче системаның (Министрлыкның) рәсми сайтында инвестиция программасына кертелә торган үзгәрешләрнең (инвестиция программасына төзәтмәләрнең) күрсәтелгән проектын урнаштырган көннән соңга калмыйча Министрлыкка гариза җибәрә.

